ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РУССКО-АЗЕЛЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, 1, с.Р.Азелеево,
Зеленодольский район, 422512

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯШЕЛ ҮЗӘН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
РУС ӘҖИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк ур., 1, Р. Әҗиле авылы,
Зеленодольск р., 422512

Тел.факс: (84371) 2-68-25. E-mail: Razl.Zel@tatar.ru, www.zelenodolsk.tatarstan.

# КАРАР

2022 елның 19 сентябре №24

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Рус Әҗиле авыл җирлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә гражданнарның катнашу формаларын билгеләү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 18 ноябрендәге 69-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә гражданнарның катнашу формаларын билгеләү максатыннан чыгып КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Рус Әҗиле авыл җирлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә гражданнарның катнашуының формалары булып торуын билгеләргә:

- эштә һәм көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү;
- үз милкендәге биналарда һәм корылмаларда янгыннарны сүндерүнең беренчел чараларының булуы;
- янгын ачыкланганда, алар турында шунда ук янгын сагына хәбәр итәргә;
- янгын сагы килгәнче кешеләрне, мөлкәтне һәм янгынны сүндерү буенча көчдән килгәнчә чаралар күрү;
- янгынны сүндергәндә янгын сагына ярдәм күрсәтү;
- дәүләт янгын күзәтчелеге вазыйфаи затларының күрсәтмәләрен һәм башка законлы таләпләрен үтәү;

законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт янгын күзәтчелегенең вазыйфаи затларына янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне контрольдә тоту һәм аларны бозуларны булдырмау максатларында үзләре карамагындагы җитештерү, хуҗалык, торак һәм башка биналарны һәм корылмаларны тикшерү

һәм тикшерү үткәрергә мөмкинлек бирү.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 31 июлендәге 15 номерлы «Янгын куркынычсызлыгын, шул исәптән Рус Әҗиле авыл жирлеге территориясендә ирекле янгын сакчылыгы эшчәнлеген тәэмин итүдә гражданнарның катнашу формаларын билгеләү турында» карары үз көчен югалткан дип танырга;

-2021 елның 25 маеннан «Рус Әҗиле авыл җирлеге территориясендә, шул исәптән Рус Әҗиле авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 31 июлендәге 15 номерлы карары белән расланган янгын куркынычсызлыгы буенча гражданнарның катнашуы формаларын билгеләү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru һәм Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайты составында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм түбәндәге адреслар буенча мәгълүмати стендларда: Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Рус Әҗиле авылы, Үзәк урамы, 1 йорт, Карашам авылы, Новая урамы, 27 йорт (СДК бинасы)

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Рус Әҗиле авыл җирлеге башлыгы Г.Ф.Семахина